# ШӨБҺӘ БАР, ҖАВАБЫ ДА...

## АВГУСТ КРИЗИСЫ КАБАТЛАНМАСМЫ?

**Аналитиклар август аенда девальвация була дип кисәтә. Экспертлар фаразлавынча, илдәге социаль-икътисади вазгыять 1998 елдагы кризиска якын.**

ИКЪТИСАД

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**



Анна АРАХАМИЯ фотосы

Петербургтагы «Интересант» журналы эксперты Николай Печерников августны хәтта «кара ай» булырга мөмкин ди. Ул моны Россиядә акча резервы бетеп бару, шуңа өстәп, коронавирус пандемиясенең дә тискәре тәэсире булу белән аңлата.

«Россия алтынны сатып алучы түгел, сатучы бердәнбер ил. Бу факт та илдә финанс чаралары җитмәү турында сөйли», – дип яза «Дейта». Әмма икътисадчы Максим Кривелевич мондый фикерләр халык арасында паника гына тудыра, негатив фаразлар аркасында кешеләр уйламаган адымнар ясап, кирәкмәгән әйберләр яки кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга мөмкиннәр, дигән шик белдерә. Алтын мәсьәләсенә килгәндә, «алтынны күп сату турында түгел, газны гадәтләнгәннән азрак сатуыбыз турында сөйләү дөресрәк» ди ул.

Экспертларның фаразы никадәр дөрес булырга мөмкин булуы турында без Казан федераль университеты профессоры, икътисад фәннәре докторы Игорь Кохтан сораштык. Аның фикеренчә, Россиядәге хәзерге вазгыять 1998 елгы кризиска берничек тә охшамаган.

– Ул вакытта безнең бернинди дә финанс резервлары булмады. Илкүләм иминлек фонды оештырылмаган, ә алтын валютасы резервы хәзергегә караганда 25 тапкырга азрак, салым җыемы да якынча 50 процент иде. Дәүләтнең тышкы бурычы, бүгенге белән чагыштырып әйткәндә, биш тапкырга күбрәк булды. Ул вакытта кулланыла торган товарларның яртысы диярлек читтән кертелде. Нефть исә 15 доллар тора иде. 1998 елгы кризисның кабатлануы мөмкин түгел, – диде ул.

Алтынга килгәндә, икътисадчы Россия иң эре алтын җитештерүче һәм читкә чыгаручыларның берсе булып тора дигән фикердә. Хәзер дә алтын резервтан сатылмый, башка вакыттагы кебек, агымдагы керемнәрдән, ди спикер. Алтынны сатудан кергән акчаның газны саткан акчадан артып китүен исә фәкать газга бәянең түбән, ә алтынныкы бик югары булуы белән аңлатты.

# Мишустин туристларга да акча өләшә

## ТУРИЗМ БУЕНЧА ФЕДЕРАЛЬ АГЕНТЛЫК ШӘП КЕНӘ ПРОГРАММА ТӘКЪДИМ ИТӘ

**Дәүләт кабат акча өләшә, төгәлрәге, акчаны кире кайтара. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин Россиядә ял иткән туристларга юлламаларының бер өлешен кире кайтарырга вәгъдә бирде.**

ОТЫШЛЫ ЯЛ

**Лилия ЛОКМАНОВА**

– Узган атнада Хөкүмәт эчке туризмны үстерер өчен 15 млрд сум күләмендә акча бүлеп бирергә карар кылды. Бу акча ел азагына кадәр Россиядә ял итәргә ниятләгән туристларга чыгымнарының бер өлешен кире кайтаруга тотылачак, – ди Мишустин.

Россиянең Туризм буенча федераль агентлыгы тәкъдим иткән программа кысаларында, юллама бәясе 25-75 мең сум күләмендә булган очракта, компенсация кайтару мөмкинлеге бар. Әмма тур «МИР» түләү системасы аша узган булуы шарт.

Һәр шундый тур өчен 5 мең сум, юллама бәясе 50 меңнән артса – 10 мең, 75 мең сумнан артканда 15 мең сум күләмендә акчаны кире кайтарачаклар. Шул рәвешле, Ростуризм 2 млн юлламаны компенсацияләргә планлаштыра һәм бу программа инде август аенда ук тормышка ашырыла башлаячак.

Шартларга килгәндә, «МИР» системасы әле аларның «чәчәге» генә. Беренчедән, сез сайлаган тур Туризм комитеты тәкъдим иткән исемлеккә кергән булырга тиеш. Шулай ук турны Бердәм федераль реестрда теркәлгән тур операторыннан алу кирәк. Юллама кимендә 5 төнгә исәпләнгән булуы шарт. Программа елга туризмы, экологик, авыл һәм мәдәни-күңел ачу туризмы юнәлешләрендә алынган юлламаларга кагыла.

Акчаны ничек кайтарыргамы? Иң элек мирпутешествий.рф сайтына керергә, партнерларның берсенең тәкъдимен сайларга һәм аларның сайтына күчәргә кирәк. Анда акциядә катнаша торган турны сайлап, сатып алырга була. Биш көн эчендә әлеге турга кэшбек картагызга кайтарылачак. Кемгәдер биш минут эчендә дә кайтарылырга мөмкин.

«Интерфакс» хәбәр итүенчә, компенсацияне Ростов, Псков, Иркутск, Волгоград, Самара, Ярославль, Свердловск, Новосибирск, Сахалин, Түбән Новгород, Саратов, Архангельск, Ленинград, Смоленск, Әстерхан, Волгоград, Тула, Төмән, Воронеж, Кемерово, Тверь, Новгород, Оренбург, Владимир, Чиләбе өлкәләре, Кабардин-Балкар, Мордовия, Башкортстан, Карелия, Удмуртия Республикалары, Краснодар, Хабаровск крайлары, Ханты-Мансийск автоном округы һәм, әлбәттә инде, Татарстанга килүчеләргә бирәчәкләр. Гомумән алганда, бу исемлеккә 45 субъект кертелгән. Номер фонды аз булган Бурятия, Хакасия, Камчатка, Кострома, Иваново, Ульяновск кебек өлкәләргә юллама алучыларның да компенсация алу мөмкинлеге бар.

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Лагерь янәшәдә булса, ял итәргә ярый

**«Без Казанда яшибез. Быелгы җәйдә баламны Санкт-Петербургта урнашкан интернациональ лагерьга җибәрергә теләгән идем. Әмма күптән түгел генә баланы башка субъекттагы лагерьга озатырга ярамавын белдем. Бу чыннан да шулаймы?**

**Н.Кирина».**



Р. Гали фотосы

РФ Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 30 июнендәге 16нчы карары белән расланган «Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралу шартларында балалар һәм яшьләр өчен белем бирү оешмалары һәм башка социаль инфраструктура объектларының эшен оештыру, аларның эчтәлеге һәм төзелешенә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» нигезендә, балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү Россия Федерациясе субъекты чикләрендә аларның фактик яшәү урыны буенча оештырылырга тиеш. Биредә Арктика зонасында яшәгән балалар гына искәрмә була ала.

**Федераль әһәмияткә ия шәһәрләрдә яшәгән балаларның ялын оештыру һәм сәламәтләндерү Россия Федерациясенең алар белән чиктәш субъектларында гамәлгә ашырылырга мөмкин.**